КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 август г.Казань № 946

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы; 2022 ел, 9 июль, 661 нче; 2022 ел, 6 сентябрь, 964 нче, 2022 ел, 16 ноябрь, 1218 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1483 нче, 2023 ел, 14 апрель, 462 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында» 2005 елның 28 апрелендәге ПУ-147 номерлы Указы белән» сүзләрен «Татарстан

Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы белән» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «2005 ел» сүзләрен «тиешле финанс елы һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы» сүзләрен «вәкаләтле республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта «предприятиеләр, учреждениеләр һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5 пунктта «җирле үзидарәсе» сүзләренә кадәр «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчаның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.4 пунктчада:

уналтынчы абзацта «предприятиеләр, учреждениеләр һәм башка» сүзләрен төшереп калдырырга;

унҗиденче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга, «предприятиеләр, учреждениеләр һәм башкалар» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3.9 пунктчада:

җиденче абзацта «җирле үзидарәсе» сүзләренә кадәр «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.11 пунктның утыз өченче абзацында «башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.12 пунктчада:

сигезенче абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «үзидарәләр» сүзенә кадәр «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктчаның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

әлеге Нигезләмәгә кушымта исемендә «предприятиеләр, учреждениеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләү турында» 2017 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 14 апрель, 462 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Табигать ресурслары торышы турында һәм Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитын саклау хакында еллык дәүләт докладын әзерләү турында нигезләмәдә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының эш режимнары турында тәкъдимнәр әзерләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2019 ел, 9 август, 664 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 09 август, 664 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының эш режимнары турында тәкъдимнәр әзерләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәнең 15 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының эш режимнары турында тәкъдимнәр әзерләү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составында:

комиссия составыннан Т.Р.Гыйләҗевны, Ф.Г.Минһаҗевны, Л.Р.Сафинны, И.Ә.Фәйзуллинны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Артемьев Артем Викторовичны | Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге башлыгын (килешү буенча) |
| Кудряшев Владимир Николаевичны | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасарын |
| Тугушев Алмаз Абзал улын | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры урынбасарын |
| Хәнифов Фәрит Мөдәрис улын | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрын |
| Хуртина Евгения Игоревнаны | «Үзәк төбәк су хуҗалыгы» федераль дәүләт бюджет су хуҗалыгы учреждениесенең «Урта идел су хуҗалыгы» филиалының төзелеш һәм су хуҗалыгы чаралары бүлеге башлыгы урынбасарын (килешү буенча); |

Шинкарев Михаил Александрович вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балыкчылык федераль агентлыгының Идел-Кама территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча су биологик ресурсларын дәүләт контролендә тоту, аларга күзәтчелек итү һәм аларны саклау бүлеге башлыгы (килешү буенча)».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип таныргa:

«Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турында» 2015 ел, 30 апрель, 305 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турында» 2015 ел, 30 апрель, 305 нче карары белән расланган «Чиста караш» ачык республика яшьләр социаль экологик реклама конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында 2017 ел, 24 ноябрь, 899 нчы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин